МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**06.06.2019** Казан ш. **№272**

Фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләрне башкаруга һәм инновацион проектларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын тоту системасының нәтиҗәлелеген арттыру һәм камилләштерү чаралары турында

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Инновацион һәм фәнни-техник эшчәнлеккә дәүләт ярдәме өлкәсендәге чаралар кысаларында киләчәктә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителә торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләргә һәм инновацион проектларга экспертиза үткәрүне оештыру тәртибен (кушымтада бирелә) (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Инновацион эшчәнлек бүлегенә (Д.И.Луньков) тәэмин итәргә:

инновацион һәм фәнни-техник эшчәнлеккә дәүләт ярдәме өлкәсендәге чаралар кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт программаларына кертелә торган, алга таба Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителә торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләрне һәм инновацион проектларны экспертизага җибәрү өчен дәүләт заказчыларыннан заявкалар кабул итүне һәм теркәүне;

бирелгән документларның һәм андагы белешмәләрнең билгеләнгән тәртип таләпләренә һәм шартларына туры килүен тикшерүне;

инновацион һәм фәнни-техник эшчәнлеккә дәүләт ярдәме өлкәсендәге чаралар кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт программаларына кертелә торган, алга таба Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителә торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләргә һәм инновацион проектларга экспертиза оештыруны;

киләсе елның 1 апреленә кадәр дәүләт заказчылары тарафыннан формалаштырылган фәнни-тикшеренү эшләрен башкару, инновацион проектларны гамәлгә ашыру турындагы хисаплар нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын тотуның нәтиҗәлелегенә анализ ясарга һәм киләсе елларга фәнни-тикшеренү эшләрен башкаруга һәм инновацион проектларны гамәлгә ашыруга дәүләт заказын формалаштыру стратегиясен билгеләргә.

3. Әлеге Боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны министр урынбасары И.Р.Киреевага йөкләргә.

**Министр** **Ф.С. Габделганиев**

| | |
|---|---|
| Килештерелде:<br>Татарстан Республикасы<br>Фәннәр академиясе президенты<br><br>_________________ М.Х.Сәлахов | Татарстан Республикасы<br>Икътисад министрлыгының<br>2019 елның «__»__________<br>_____ номерлы боерыгы<br>белән расланды |

Инновацион һәм фәнни-техник эшчәнлеккә дәүләт ярдәме өлкәсендәге чаралар кысаларында киләчәктә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителә торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләргә һәм инновацион проектларга экспертиза үткәрүне оештыру тәртибе

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге нигезләмә «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Татарстан Республикасында фән, технологияләр һәм техника үсешенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 ноябрендәге 2957-р номерлы боерыгы белән расланган өстенлекле юнәлешләре буенча инновацион һәм фәнни-техник эшчәнлеккә дәүләт ярдәме өлкәсендәге чаралар кысаларында алга таба гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителә торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләргә һәм инновацион проектларга экспертиза үткәрүне оештыру тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Тәртиптә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

инициатор – оешу-хокук формасына бәйсез рәвештә, Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән, фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләрне (алга таба – фәнни-тикшеренү эшләрен) гамәлгә ашыру, югары технологияле, конкуренциягә сәләтле продукция чыгаруга юнәлтелгән инновацион проектларны гамәлгә ашыру инициаторы булган юридик затлар;

дәүләт заказчылары – югары технологияле, конкуренциягә сәләтле продукция җитештерүгә юнәлдерелгән фәнни-тикшеренү эшләренә, инновацион проектларга дәүләт заказчыларын урнаштыручы, дәүләт программаларының дәүләт заказчысы-координаторлары булып торучы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары.

1.3. «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә инновацион һәм фәнни-техник эшчәнлеккә ярдәм итү өлкәсендәге чараларны үз эченә алучы дәүләт программаларына финанслау күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән елына иң күбе 10 млн.сум тәшкил иткән, югары технологияле, конкуренциягә сәләтле продукция җитештерүгә юнәлдерелгән фәнни-тикшеренү эшләре, инновацион проектлар кертелә, шул исәптән түбәндәгеләргә дә:

яңа фән сыйдырышлы продукциянең, яңа материалларның, приборларның, программа продуктларының сынау үрнәген, прототибын булдыру яки булган технологияләрне камилләштерү өчен;

проект-конструкторлык, норматив-методик документлар эшләү өчен;

фәнни, фәнни-техник һәм инновацион программалар эшләү өчен;

кулланма, фаразый, аналитик, статистик, экологик, маркетинглы, патентлы һәм башка тикшеренүләр эшләү өчен;

фәнни-техник һәм инновацион эшчәнлек инфраструктурасын үстерү чараларын эшләү, шул исәптән фәнни-техник һәм инновацион продукцияне, яңа технологияләрне коммерцияләштерү өчен старт шартларын тәэмин итү өчен.

## II. Фәнни-тикшеренү эшләренә экспертиза үткәрү тәртибе һәм шартлары, фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр башкаруга һәм (яки) инновацион проектларны гамәлгә ашыруга заявкалар

2.1. Инициатор фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләрне башкаруга һәм (яки) инновацион проектларны гамәлгә ашыру турында әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасына туры китереп билгеләнгән форма буенча гариза (алга таба – заявка) бирү юлы белән, фәнни-тикшеренү эшләрен башкару, инновацион проектларны гамәлгә ашыру инициативасы белән агымдагы елның 1 февраленә кадәр дәүләт заказчысына мөрәҗәгать итә.

2.2. Инициатор гариза бирү датасына түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган салым салуның ташламалы салым режимын бирүче һәм (яки) юридик затларга (оффшор зоналарга) карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм тапшыруны күздә тотмаучы дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләттә яки территориядә теркәлгән чит илләрнең юридик затларының катнашу өлеше җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артып китмәгән Россия юридик заты булып тормаска;

үзгәртеп кору, бетерелү яки бөлгенлеккә төшү процессында тормаска;

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмаска;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, шул исәптән башка хокукый актлар нигездә дә бирелгән бюджет инвестицияләрен кайтарып бирү буенча вакыты узып киткән әҗәтләргә һәм Татарстан Республикасы бюджетына түләүдә вакыты узган башка әҗәтләргә, шулай ук бирелгән бюджет акчаларын максатына ярашсыз рәвештә һәм (яки) нәтиҗәсез файдалану турында җинаять яки административ җаваплылыкка тарту турында үз көченә кергән актлар белән расланган фактларга ия булмаска;

фәнни-тикшеренү эшләрен башкаруга, фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләрне башкаруга һәм (яки) инновацион

проектларны гамәлгә ашыругабүтән норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булып тормаска;

Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алу өчен фәнни-тикшеренү эшләрен башкаруга, инновацион проектларны гамәлгә ашыруга заявка тапшыру датасына уртача айлык хезмәт хакы дәрәҗәсен Татарстан Республикасында хезмәткә сәләтле халык өчен билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән киметмәскә.

2.3. Әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән заявкага түбәндәге документлар теркәлә:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашыруга планлаштырыла торган фәнни-тикшренеү эшләрен башкаруга, инновацион проектларны гамәлгә ашыруга инициатор җитәкчесе тарафыннан расланган чыгымнар сметасы, аларның күләмен нигезли торган мәгълүматларны күрсәтеп, чыгымнарның планлаштырыла торган юнәлешләре калькуляциясен үз эченә алган финанс-икътисадый нигезләүне теркәп;

фәнни-тикшеренү эшләрен башкаруга, инновацион проектларны гамәлгә ашыруга фәнни-техник эшне, инновацион проектны финанслауның гомуми күләменнән кимендә 50 проценты күләмендә бюджеттан тыш чыганаклардан алынган (шәхси акча һәм (яки) өченче затлардан җәлеп ителгән акча) акча булуы турында документаль дәлилләмә (шул ук вакытта күрсәтелгән акчаның кимендә 20 проценты фәнни-тикшеренү эшләренә кулланыла);

инициаторның гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга барлык үзгәрешләр турында документлар күчермәләре;

инициаторның әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында инициаторның җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имзаланган белешмә.

Документлар кәгазьдә бер нөсхәдә, шулай ук MS Office форматында электрон рәвештә тапшырыла.

Инициатор Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы өчен җавап тота.

2.4. Дәүләт заказчылары инициаторлар тарафыннан тәкъдим ителгән заявкаларны һәм документларны тиешле тармакларда дәүләт программалары өстенлекләрен исәпкә алып карый һәм агымдагы елның 1 мартына кадәр аларны, экспертиза оештыру өчен, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – Министрлык) юллыйлар.

2.5. Министрлык заявкалар һәм документлар кергән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнүче 10 көнлек срокта аларны экспертиза уздыру өчен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә җибәрү мөмкинлеге турындагы мәсьәләне хәл итү максатларында, аларны тикшерә, шул исәптән инициаторларның әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе буенча да.

Инициаторлар тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөреслеген тикшерү ведомствоара хезмәттәшлек аша мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән тормышка ашырыла.

Инициаторның әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве, шулай ук инициаторлар тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөрес булмавы яки әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән документларның

булмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы) Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә заявкалар җибәрүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Бу очракта Министрлык, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән вакыт чикләрендә, дәүләт заказчысына һәм инициаторга, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә заявканы җибәрүдән баш тарту турында хәбәр җибәрә.

Инициаторлар, хәбәр алынган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек срокта, ачыкланган җитешсезлекләрне бетергәннән соң заявканы яңадан Министрлыкка җибәрергә хокуклы.

Министрлык, агымдагы елның 1 апреленнән соңга калмыйча, экспертиза үткәрү өчен заявкаларны һәм документларны Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә җибәрә.

2.6. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, заявкалар һәм документлар кабул ителгән көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә, фәнни-тикшеренү эшләренә, инновацион проектларга әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасына туры китерелгән бәяләү критерийлары нигезендә фәнни-техник һәм финанс-икътисадый экспертиза үткәрә.

Заявкаларны критерийлар буенча бәяләү өчен биш баллы бәяләү шкаласы кулланыла.

Эксперт гаризада тәкъдим ителгән мәгълүматны сыйфаты һәм күләме буенча бәяләү өчен һәр критерий күрсәткече буенча мантыйкый-интуитив анализ ясый һәм тапшырылган белешмәләрнең заявканың предмет өлкәсенә (күләм һәм сыйфат характеристикаларына) туры килү дәрәҗәсен исәпкә алып, профессиональ, фәнни һәм гамәли тәҗрибә нигезендә бәяләмә чыгара.

2.7. Фәнни-тикшеренү эшләренә, инновацион проектларга экспертиза тармак сегментлары кысаларындагы юнәлешләр буенча кимендә өч эксперт составындагы эксперт төркемнәре тарафыннан гамәлгә ашырыла. Эксперт төркемнәренең составы Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе боерыгы белән формалаштырыла һәм раслана.

Экспертиза үткәргәндә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хокуклы:

инициатордан фәнни-тикшеренү эшләре, инновацион проектлар турында өстәмә мәгълүмат соратып алырга;

инициаторлар белән килешеп, бәйсез профессиональ белгечләрне (экспертларны) җәлеп итәргә.

Экспертиза субъектлары Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дәүләт, коммерция, хезмәт һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрнең яклануын тәэмин итә.

2.8. Экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча һәр тармак сегментында дәүләт программасына кертелүгә тәкъдим ителә торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр башкаруга һәм (яки) инновацион проектларны гамәлгә ашыруга әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасына туры китерелгән формада баллар кимү тәртибендә заявкалар рейтингы төзелә (алга таба – заявкалар рейтингы).

Экспертиза нәтиҗәләре һәм Заявкалар рейтингы нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе фәнни-тикшеренү эшләренә, инновацион

проектларга эксперт бәяләмәләрен рәсмиләштерә һәм аларны һәм Заявкалар рейтингы нәтиҗәләрен әлеге Тәртипнең 2.6 пунктында билгеләнгән вакыт кысаларында Министрлыкка җибәрә.

2.9. Эксперт бәяләмәләре һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тәкъдим иткән Заявкалар рейтингы нәтиҗәләре, шулай ук алдагы чорда фәнни-тикшеренү эшләрен башкаруга һәм инновацион проектларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын тотуның нәтиҗәлелеген анализлау нәтиҗәләре нигезендә Министрлык, аларны алган вакыттан башлап эш көннәрендә исәпләнгән 30 көнлек срокта, тиешле финанс елына һәм план чорына фәнни-тикшеренү эшләрен, инновацион проектларны финанслау күләмнәрен һәм аларның дәүләт заказчыларын билгеләп, фәнни-тикшеренү эшләренең, инновацион проектларның исемлеген төзи һәм аны Татарстан Республикасының фәнни-техник һәм инновацион сәясәт буенча хөкүмәт комиссиясенә раслау өчен җибәрә.

2.10. Фәнни-тикшеренү эшләрен, инновацион проектларны исемлеккә кертүдән баш тарту өчен нигез булып Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең фәнни-тикшеренү эшләренә, инновацион проектларга тискәре эксперт бәяләмәләре тора.

Бу очракта Министрлык Татарстан Республикасы Фәннәр академиясеннән фәнни-тикшеренү эшләренә, инновацион проектларга эксперт бәяләмәсен һәм Заявкалар рейтингын алган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнүче биш көнлек срокта дәүләт заказчысына һәм инициаторга хәбәр җибәрә.

2.11. Фәнни-тикшеренү эшләренең, инновацион проектларның расланган исемлеге һәм Татарстан Республикасы бюджетында каралган акчалар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм максатчан ведомство программаларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 елның 31 декабрендәге 1199 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм максатчан ведомство программаларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе нигезендә фәнни-тикшеренү эшләрен башкару һәм инновацион проектларны гамәлгә ашыру чараларын аларда чагылдыру өлешендә дәүләт программаларына тиешле үзгәрешләр кертү өчен нигез булып тора.

2.12. Министрлык фәнни-техник продукциягә компетенцияләр һәм ихтыяҗлар базасын формалаштыру өчен башкарылган эшләр турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә тапшыра.

Инновацион һәм фәнни-техник эшчәнлеккә дәүләт ярдәме өлкәсендәге чаралар кысаларында киләчәктә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителә торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләргә һәм инновацион проектларга экспертиза үткәрүне оештыру тәртибенә 1 нче кушымта

**Фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләрне башкаруга һәм (яки) инновацион проектларны гамәлгә ашыруга заявка**

1. Фәнни-тикшеренү эшенең (инновацион проектның) исеме:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

2. Фәнни-тикшеренү эшенең (инновацион проектның) максаты:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

3. Фәнни-тикшеренү эше (инновацион проект) аны хәл итү өчен юнәлдерелгән проблема ____________________________________________________________
______________________________________________________________________

4. Югары технологияле, конкуренциягә сәләтле продукция җитештерүгә юнәлдерелгән фәнни-тикшеренү эшләрен башкаруга, инновацион проектны гамәлгә ашыруга дәүләт заказын урнаштыручы дәүләт заказчысы турында мәгълүмат:

4.1. Тулы атамасы:
______________________________________________________________________

4.2. Юридик затның урнашу урыны:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

4.3. Элемтә өчен ______________________________________________________
4.4. Телефон / факс ___________________________________________________

4.5. E-mail __________________________________________________________

5. Аның нигезендә фәнни-тикшеренү эше башкарылачак, инновацион проект гамәлгә ашырылачак дәүләт программасының исеме ________________________
____________________________________________________________________________

6. Югары технологияле, конкуренциягә сәләтле продукция җитештерүгә юнәлдерелгән фәнни-тикшеренү эшләрен башкаруның, инновацион проектны гамәлгә ашыруның инициаторы булган оешма турында мәгълүматлар

6.1. Оешманың тулы исеме:
____________________________________________________________________________

6.2. Юридик затның урнашу урыны:
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

6.3. Элемтә өчен _______________________________________________________

6.4. Телефон / факс _____________________________________________________

6.5. E-mail _________________________________________________________

7. Алга таба Татарстан Республикасы бюджеты акчасы хисабыннан гамәлгә ашыру һәм күрсәтелгән фәнни-тикшеренү эшен (инновацион проектны) финанслау өчен дәүләт программаларына кертү өчен тәкъдим ителгән фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләргә һәм инновацион проектларга экспертиза уздыру тәртибенең 2 нче кушымтасына туры китерелгән критерийлар нигезендә фәнни-тикшеренү эшенә (инновацион проектка) сыйфатлама

*(фәнни-тикшеренү эшенең, инновацион проектның кыскача тасвирламасын, фәнни-тикшеренү эшен башкаруга, инновацион проектны гамәлгә ашыруга календарь планын, социаль-икътисадый нәтиҗәлелекнең төп күрсәткечләрен һәм аларның еллар буенча күрсәткечләрен, продукцияне сату базарын һәм төп кулланучыларын, патенты яклануын, Россия Федерациясе дәүләт программалары һәм башка проектлар һәм программалар белән бәйләнешен һ.б. күрсәтеп.)*

__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________

8. Тәкъдим ителүче фәнни-тикшеренү эшен (инновацион проектны) финанслауның гомуми күләме

Барлыгы– _____________ (_________________) мең сум, шул исәптән:

1) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән:
_____________ (_________________) мең сум, шул исәптән:
20_ елда– _____________ (_________________) мең сум,
20_ елда– _____________ (_________________) мең сум.

2) бюджеттан тыш чаралар хисабына:
_________________________ (финанслау чыганагы исеме)
_____________ (_________________) мең сум, шул исәптән:
20_ елда– _____________ (_________________) мең сум,
20_ елда– _____________ (_________________) мең сум.

Министрлык (ведомство)
җитәкчесе

| | |
|---|---|
| __________________ | __________________________ |
| (имза) | (Ф.И.А.) |

М.У.

Инновацион һәм фәнни-техник эшчәнлеккә дәүләт ярдәме өлкәсендәге чаралар кысаларында киләчәктә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителә торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләргә һәм инновацион проектларга экспертиза үткәрүне оештыру тәртибенә 2 нче кушымта

# ФӘННИ-ТИКШЕРЕНҮ ЭШЛӘРЕН, ИННОВАЦИОН ПРОЕКТЛАРНЫ БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЙЛАРЫ

## I. ФӘННИ-ТИКШЕРЕНҮ ЭШЛӘРЕН, ИННОВАЦИОН ПРОЕКТЛАРНЫ БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЙЛАРЫ ҺӘМ АЛАРНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ

| Кри-терий номеры | Фәнни-тикшеренү эшләрен, инновацион проектларны бәяләү критерийлары | Балларда критерийның максималь әһәмияте |
|---|---|---|
| 1. | Фәнни-техник экспертиза | |
| 1.1 | Юнәлешнең киләчәге | 5 |
| 1.2 | Эшләнмәнең техник дәрәҗәсе | 5 |
| 1.3 | Техник яктан гамәлгә ашырылу дәрәҗәсе | 5 |
| 2. | Финанс-икътисадый экспертиза | |
| 2.1 | Россия һәм халыкара базарларда фәнни-тикшеренү эшләренә, инновацион проектларга ихтыяҗ булу-булмавы | 5 |
| 2.2 | Фәнни-тикшеренү эшләренең, инновацион проектларның маркетинг яктан эшләнелеп бетү дәрәҗәсе | 5 |
| 2.3 | Инициаторның эшчәнлеге | 5 |
| 2.4 | Фәнни-тикшеренү эшләренең, инновацион проектларның эшләнелеп бетү дәрәҗәсе | 5 |
| 2.5 | Бюджет нәтиҗәлелеге | 5 |

## II. ФӘННИ-ТИКШЕРЕНҮ ЭШЛӘРЕН, ИННОВАЦИОН ПРОЕКТЛАРНЫ БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЙЛАРЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

### 1. Фәнни-техник экспертиза буенча бәяләү критерийлары

| № | Критерий күрсәткечләре | Күрсәткечнең эчтәлеге |
|---|---|---|
| 1.1 | Юнәлешнең киләчәге | Анализ үткәрелә:<br>- фәнни-тикшеренү эшләренең, инновацион проектларның Татарстан Республикасында фән, технологияләр һәм техника үсешенең өстенлекле юнәлешләренә, шулай ук 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясендә билгеләнгән максатларга һәм бурычларга туры килү-килмәвенә;<br>- импортны алыштыруга һәм эчке ихтыяҗны арттыруга юнәлдерелгән булу-булмавына;<br>- тәкъдим ителгән чишелешләрнең өстенлекләренә һәм |

| № | Критерий күрсәткечләре | Күрсәткечнең эчтәлеге |
|---|---|---|
| | | җитешсезлекләренә. |
| 1.2 | Эшләнмәнең техник дәрәҗәсе | Анализ үткәрелә:<br>- фәнни-тикшеренү эшләренең, инновацион проектларның нәтиҗәләренең дөньякүләм дәрәҗәгә туры килү-килмәвенә (фәнни-тикшеренү эшләренең башкара, инновацион проектларны гамәлгә ашыра башлаган һәм тәмамлаган вакытка);<br>- дөнья дәрәҗәсенә карата техник чишелешләрнең яңалыгына (инициатор мәгълүматлары буенча бәяләнә);<br>- фәнни-тикшеренү эшләрен башкару, инновацион проектларны гамәлгә ашыру кысаларында алынган интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә патентлар исәбенең саклануга сәләтле булуына;<br>- экологик таләпләргә туры килүенә; |
| 1.3 | Техник яктан гамәлгә ашырылу дәрәҗәсе | Анализ үткәрелә:<br>- фәнни-техник эшне һәм нәтиҗә өчен аның асылын анализлау;<br>- патент ягыннан чиста булуны, көндәшләрдән төп патентларын сатып алу (алу) зарурилыгын анализлау;<br>- фәнни-тикшеренү эшләре, инновацион проектлар нәтиҗәләренең гамәлгә кертелү дәрәҗәсен бәяләү;<br>- фәнни-тикшеренү эшләрен башкару, инновацион проектларны гамәлгә ашыру өчен срокларның нигезле булуын бәяләү;<br>- инициаторда шундый ук фәнни-тикшеренү эшләрен башкару, инновацион проектларны гамәлгә ашыру тәҗрибәсе булуны анализлау;<br>- календарь планы этапларының фәнни-тикшеренү эшләренең, инновацион проектларның эчтәлегенә һәм максатларына туры килүен бәяләү;<br>- сатып алына торган җиһазлар исемлеген бәяләү. |

**2. Финанс-икътисадый экспертиза буенча бәяләү критерийлары**

| № | Критерий күрсәткечләре | Күрсәткечнең эчтәлеге |
|---|---|---|
| 2.1 | Россия һәм халыкара базарларда фәнни-тикшеренү эшләренә, инновацион проектларга ихтыяҗ булу-булмавы | Үткәрелә:<br>- заявкалар тапшыру вакытына базарның сыйдыру дәрәҗәсенә һәм үсеш тенденцияләренә анализ;<br>- ясалачак фәнни-техник, инновацион продукциягә максатчан кулланучыларга, заказ бирүче булу-булмавына анализ;<br>- планлаштырылган сату күләме.. |
| 2.2 | Фәнни-тикшеренү эшләренең, инновацион проектларның маркетинг яктан эшләнелеп бетү дәрәҗәсе | Анализлана:<br>- заявкалар тапшыру вакытына һәм продукция базарга чыккан көнгә аналогларга карата конкурентлы өстенлекләр;<br>- максатчан базарда конкуренция дәрәҗәсе;<br>- фәнни-техник, инновацион продукцияне базарга чыгару |

| № | Критерий күрсәткечләре | Күрсәткечнең эчтәлеге |
|---|---|---|
| | | механизмы булу-булмавы;<br>- табыш алу моделенең нигезлелеге;<br>- базарга чыгару өчен административ-рөхсәт бирү процедураларының зарурилыгы (сертификацияләү, лицензияләү). |
| 2.3 | Инициаторның эшчәнлеге | Анализлана:<br>- инициаторның хәзерге финанс тотрыклылыгы;<br>- уңай кредит тарихы;<br>- салым ташламаларыннан файдалану дәрәҗәсе һәм аларның нәтиҗәгә ясалаган йогынтысы. |
| 2.4 | Фәнни-тикшеренү эшләренең, инновацион проектларның эшләнелеп бетү дәрәҗәсе | Анализлана:<br>- фәнни-тикшеренү эшләрен башкаруга, инновацион проектларны гамәлгә ашыруга планлаштырыла торган бюджет һәм бюджеттан тыш чыгымнарның нигезле булуы;<br>- ресурслар белән тәэмин итү һәм идарә итү;<br>- инициаторның башка оешмалар белән челтәр хезмәттәшлеген оештыру дәрәҗәсе (кирәк булганда);<br>- инвестицион җәлеп итүчәнлеге (NPV, IRR һәм башкалар.);<br>- фәнни-тикшеренү эшләре, инновацион проектлар нәтиҗәләрен кулланудан көтелгән социаль-икътисадый нәтиҗәлелек;<br>- фәнни-тикшеренү эшләрен башкаруның, инновацион проектларны гамәлгә ашыруның алдагы этапларында үсеш институтлары ягыннан ярдәм. |
| 2.5 | Бюджет нәтиҗәлелеге | Яңа югары квалификацияле эш урыннарын оештыру күрсәткечләре һәм фәнни-тикшеренү эшләрен башкарудан, инновацион проектларны гамәлгә ашырудан планлаштырыла торган салым түләүләре күләме анализлана. |

## III. Фәнни-тикшеренү эшләрен, инновацион проектларны бәяләү формасы

### 1. Фәнни-техник экспертиза бәясе

Экспертның Ф.И.А.:______________ Тармак сегменты___________________________Дата:_______

| № п/п | Фәнни-тикшеренү эшләренең, инновацион проектларның исеме | Балларда критерийларның әһәмияте | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Критерий № 1.1 | Критерий №1.2 | Критерий № 1.3 |
| 1. | | | | |
| 2. | | | | |
| 3. | | | | |
| … | | | | |
| БАЛЛАР СУММАСЫ: | | | | |

### 2. Финанс-икътисадый экспертиза бәясе

Экспертның Ф.И.А.:______________ Тармак сегменты___________________________Дата:_______

| № п/п | Фәнни-тикшеренү эшләренең, инновацион проектларның исеме | Балларда критерийларның әһәмияте | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Критерий № 2.1 | Критерий № 2.2 | Критерий № 2.3 | Критерий № 2.4 | Критерий № 2.5 |
| 1. | | | | | | |
| 2. | | | | | | |
| 3. | | | | | | |
| … | | | | | | |
| БАЛЛАР СУММАСЫ: | | | | | | |

Инновацион һәм фәнни-техник эшчәнлеккә дәүләт ярдәме өлкәсендәге чаралар кысаларында киләчәктә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителә торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләргә һәм инновацион проектларга экспертиза үткәрүне оештыру тәртибенә 3 нче кушымта

____________________________________________________________________

(дәүләт программасының исеме)

**дәүләт программасына кертергә тәкъдим ителә торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр башкаруга һәм (яки) инновацион проектларны гамәлгә ашыруга заявкалар рейтингы**

| № п/п | Инициатор исеме | Фәнни-тикшеренү эше һәм (яки) инновацион проект исеме | Баллар суммасының әһәмияте |
|---|---|---|---|
| 1 | | | |
| 2 | | | |
| 3 | | | |
| ... | | | |

«___» ______________ 20___ ел

____________ __________________________
/имза/ /экспертның ФИА

____________ __________________________
/имза/ /экспертның ФИА

____________ __________________________
/имза/ /экспертның ФИА

.....................